СОВЕТ ЗАИНСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ЗӘЙ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
СОВЕТЫ

**РЕШЕНИЕ** **КАРАР**

30.11.2023 г. Заинск № 301

**«Татарстан Республикасы Зәй муниципаль районында муниципаль хезмәт турында нигезләмә хакында» 2014 елның 14 мартындагы 355 номерлы Зәй муниципаль районы Советы карарына үзгәрешләр кертү турында**

«Россия Федерациясендә муниципаль хезмәт турында» 2007 елның 02 мартындагы 25-ФЗ номерлы Федераль закон, Муниципаль хезмәт турында 2013 елның 25 июнендәге 50-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Кодексы, «Муниципаль хезмәт турында Татарстан Республикасы кодексының 10 статьясына үзгәрешләр кертү хакында» 2023 елның 2 ноябрендәге 99-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы белән, Зәй муниципаль районы Уставына таянып, Татарстан Республикасы Зәй муниципаль районы Советы

## КАРАР ИТТЕ:

1. «Татарстан Республикасы Зәй муниципаль районында муниципаль хезмәт турында нигезләмә хакында» 2014 елның 14 мартындагы 355 номерлы Зәй муниципаль районы Советы карарының 9 статьясына (Татарстан Республикасы Зәй муниципаль районы Советының 14.11.2014 № 414, 04.03.2015 № 438, 21.05.2015 № 455, 16.10.2015 № 14, 18.12.2015 № 35, 26.08.2016 № 136, 15.12.2016 № 186, 29.03.2017 № 205, 05.07.2017 № 220, 07.09.2017 № 232, 10.09.2018 № 332, 22.04.2019 № 390, 30.09.2019 № 438, 11.03.2020 № 485, 03.06.2020 № 530, 11.11.2020 № 11, 03.03.2021 № 35, 07.10.2021 № 172, 04.03.2022 № 206, 27.01.2023 № 270, 10.08.2023 № 287 нче номерлы карарлары нигезендә кертелгән үзгәрешләр белән) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1) 11 өлештә икенче җөмләне төшереп калдырырга;

2) 17 өлешне үз көчен югалткан дип танырга;

3) 20 өлешне түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«20. Муниципаль хезмәткәргә классы чин бирү турындагы карар, әлеге статьяның 13 өлешендә күрсәтелгән очраклардан тыш, җирле үзидарәнең органына яисә вазыйфаи затына барлык кирәкле документлары булган классы чиннар бирү турындагы тапшыру кертелгән көннән алып бер айдан да соңга калмыйча кабул ителергә тиеш.».

2. Зәй муниципаль районы Советының оештыру бүлегенә әлеге карарны массакүләм мәгълүмат чараларында бастырып чыгарырга, Татарстан Республикасы хокукый мәгълүмат рәсми порталында (PRAVO.TATARSTAN.RU) һәм Зәй муниципаль районының рәсми сайтында урнаштырырга.

3. Әлеге карар рәсми басылып чыккан көненнән үз көченә керә.

4. Карарның үтәлешен контрольдә тотуны Татарстан Республикасы Зәй муниципаль районы башлыгы урынбасары П.С. Уразайкинга йөкләргә.

**Совет Рәисе** **Р.Г.Кәримов**